**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
«Левашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Левашево торак пунктында

**2024 елның 11 апреленнән** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Левашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Левашево торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1.«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Левашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Левашево торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында» 2023 елның 13 октябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәреш кертергә, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

-су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

-торак пункт территориясен төзекләндерү.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Левашево авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Татарстан Республикасы Алексеевск**
**муниципаль районы Левашево авыл**
**җирлеге башлыгы** **С.А. Демидова**